**МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казань **БОЕРЫК**

29.05.2019 № 216

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 28.01.2019 № 38 «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

2014 ел 21 нче июль № 212-ФЗ «Россия Федерациясендә Иҗтимагый контроль нигезләре турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.11.2010 № 906 «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында» карары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 28.01.2019 № 38 «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында» боерыгына (алда - Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерык преамбуласында «(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.10.2011 № 856, 24.10.2013 № 793, 20.09.2014 № 669, 14.05.2015 № 341, 05.09.2015 № 643, 17.11.2015 № 862, 10.10.2017 № 781, 24.08.2018 № 708, 07.11.2018 № 983 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)» сүзләрен төшереп калдырырга;

Боерык белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәдә:

2.2 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

"җәмгыятьтә коррупцион гамәлләргә түземсезлекне формалаштыру.»;

5.12 пунктының икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

2. Биредәге Боерыкны үтәү контролен үземә калдырам.

Министр вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Н.В. Суржко